| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**ГЛАВА**<br>**Старосляковского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Иске Эсләк авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.11.2023 Иске Эсләк авылы № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иске Эсләк авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге Уставының 14 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге Башлыгы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Иске Эсләк торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2023 елның 27 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: “2024 елда үзара салым акчаларын кертү өчен «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иске Эсләк авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, I төркем инвалидлардан, студентлардан тыш, көндезге формада белем алучы гражданнардан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, ирекле киткән) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатыннарын, балигъ булмаган балаларын) түләүдән азат итү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юллау белән килешәсезме:

1. **Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау**:

1.1 электр товарлары сатып алу.

**2. Су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аларны чистарту, транспортировкалау һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау:**

2.1 су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу мөмкинлеген тәэмин итүче су манараларын су белән тәэмин итү системасын ремонтлау һәм су бүлеп бирү өчен материаллар сатып алу;

2.2 су башнясы коймасы (материаллар сатып алу: торбалар, профнастил һәм саморезлар);
2. җирлекне су белән тәэмин итү(тирән насослар сатып алу һәм ремонтлау, сууткәргеч челтәрен ремонтлау).

**3. Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау һәм алар тирәсендәге территорияләрне төзекләндерү:**

3.1 үлән һәм чүп үләннәрен чабу, кешеләрнең тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудырган аварияле һәм коры яшеллекләрне кисү;
3.2. рөхсәтсез чүплекләрне бетерү.

**4. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:**

4.1 ягулык-майлау материаллары;
4.2 запчастьләр сатып алу.

**5. Янгынга каршы резервуарларны (янгын сүндерү сулыкларын), янгын сүндерү пирсларын төзү, ремонтлау.**

«РИЗА» «КАРШЫ».

6. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Иске Эсләк авылы, Клуб урамы, 1 йорт, авыл мәдәният йорты.

7. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

10. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Д.М. Әхмәтов